РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

***Постановление*** ***Карар***

***25*** ***г.Чистополь*** ***28.02.2022***

2022 елга гражданнар кеременең һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күрсәткечләрен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 49,51 статьяларына таянып, «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән салым салынырга тиешле мөлкәтнең хакын билгеләү методикасы, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «2021 елның I кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынының бер квадрат метр гомуми мәйданының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2020 елның 24 декабрендәге 852/ пр номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2022 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында карар кабул итү өчен иң чик мәгънәләрне билгеләргә:

1.1 гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләме: гаиләнең һәр әгъзасына - 641 286 сум.

1.2 гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме – 15 607 сум.

2. Чистай шәһәре Башкарма комитетының Торак сәясәте бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктларында күрсәтелгән күрсәткечләрне файдаланырга, гражданнарны социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗлар дип танырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Чистай шәһәре Башкарма комитетының торак сәясәте бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru/) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чистай шәһәре Башкарма

комитеты җитәкчесе урынбасары Ф.М. Садыйковка йөкләргә.

Шәһәр Башкарма
Комитеты җитәкчесе И.Ф. Рәхимов